АБД-ЭЛЬ-МАШИ

# ХРИСТОС ТУРЫНДА СИН НӘРСӘ УЙЛЫЙСЫҢ?

07.151
Что ты думаешь о Христе?
На татарском языке
What do you think about Christ?
in Tatar
© 1992 by Licht im Osten
© 1996 «Свет на Востоке»

# ГАЙСӘ – ХРИСТОС ТУРЫНДА СИН НӘРСӘ БЕЛӘСЕҢ?

Дөнья узенең ахырына ашыга. Кояш астындагы бөтен әйберләрнең ахыры якынлаша. Алладан курыккан һәм дин белән кызыксынган һәрбер кеше Гайсәнең Алладан бу дөньяга яадан киләсен белә. Шул ук вакытта Аның килуе турында белмәуләре өчен чын куңелдән шаккатырлар, чөнки алар Аның шәхесенең әһәмиятен һәм Аның барлыгын һәм бәхәссез кодрәтен кире какканнар иде.

Син узең дә Аның пәйдә булган вакытында синең хәзерге һәм киләчәк тормышың тулысы белән Синең Гайсәгә карашыннан торачагын белерсең.

Әгәр син Гайсә шәхесен таныйсың, бар дип уйлыйсың икән, син киләчәккә тыныч куңел белән, шатланып карый аласың. Тормышыңдагы бөтен сораулар Аның ярдәме белән чишелерләр, чөнки Гайсәдә танып-белунең бөтен байлыклары тупланган.

Киләчәкта синнән сорарлар: „Син Минем турында нәрсә уйлыйсың?“ Әйдәгез, бергәләп Гайсә шәхесе турында, Аның тормышы турында сөйләшик! Аның мәрхәмәтлелеге һәм рәхимлелеге аркасында син узеңнең куңелеңдә һәм йөрәгеңдә тынычлык табарсың.

# ГАЙСӘНЕҢ ТУУЫ ТУРЫНДА СИН НИНДИ ФИКЕРДӘ?

Үткәннәрдә дә, хәзерге тормышта да бер генә шәхес тә Гайсә кебек тумаган. Чөнки Ул Мәрьям улы дип аталган. Исмәгыйль – Ибраһим улы, Яхъя – Зәкәрия улы, а Мөхәммәт – Абдулла улы. Барлык кешеләр дә әтиләре исеме белән аталып йөртелә. Ни өчен соң Гайсә бары тик үзенең әнисенең исеме белән генә аталган? Чөнки аның атасы юк. Ул кыз кешедән туган! Аның яралуы һәм туы Алладан һәм Аның кодратеннән булган.

Гайсә туганчы 700 ел элек, Исайя пәйгамбәр болай дип әйткән: (Исайя 7,14) „Менә бер гыйффәтле кыз буйга узачак һәм Ир Бала тудырачак, һәм Аңа Еммануил исеме кушылачак. Ә бу – „Алла безнең белән“, – дигәнне аңлата“. Һәм менә Алла үзенең әйткән сүзен тормышка ашырды, чөнки Ул турылыклы һәм гадел, һәм Ул булдыра алмастай берни дә юк. Син Гайсәнең – Алла Сүзе икәнлеген беләсеңме? Инжилдә Алланың ачышын укы, ул болай дип әйтә: „Иң әүвәл Сүз барлыкка килде, һәм Сүз Алланыны иде. Алла-Ходай һәм Сүз үзе Алла иде. Алла һәм Сүз Аллада иде. һәм Сүз тан булды һәм безнең арабызда яшәде“. Шулай итеп, куәтле Алла Сүзе“! Сүздә гәүдәләндерелгән Гайсәдә чагылыш тапты. Әгәр дә син Аның туы турындагы вакыйгаларны уйласаң, син гажәпкә калырсың, чөнки бер генә кеше дә бу дөньяга Мәрьям улы кебек

килмәгән. Ул гаҗәеп, үзенең тууы белән чагыштыргысыз.

Син хәтерлисең микән, Алла Адәмне җир тузаныннан ясаган. Без барыбыз да Адәм уллары, һәм пәйгамбәрләр дә Адәмнән туганнар. Без барыбыз да җир кешеләре, бары тик Гайсә генә югарыдан. Чөнки ул Күктән килгән, шуңа күрә Ул гына гөнаһсыз, чиста, изге. Ә без гөнаһлылар, без җир кешеләре, ә Алла Җаныннан туганнар түгел.

Изге китаптан без, Гайсә бу дөньяга гөнаһлыларны коткарырга килгән, – дип укыйбыз. Шуңа күрә беркем дә Аның урынын яулый һәм Коткаручы исемен ала алмый, чөнки Аннан башкалар бар да җир тузаныннан туган, бары Ул гына Алладан барлыкка килгән. Ул безне, гөнаһлы жир кешеләрен кире какмый һәм безне коткару өчен зенең хезмәтләренә керешә. Ул бу бәхетсез дөньяга безне гөнаһларыбыздан арындыру өчен килгән. Шуңа күрә без Алланы Гайсәнең гаҗәеп тууы өчен олылыйбыз.

# СИҢА ГАЙСӘНЕҢ ГАЕПСЕЗЛЕГЕ, ГӨНАҺСЫЗЛЫГЫ ТУРЫНДА НӘРСӘ БИЛГЕЛЕ?

Гайсә Алла Рухыннан туган һәм үзенең тууыннан бирле гаепсез, гөнаһ кылмаган, хәтта бер тапкыр да. Ул беркайчан да дөрес булмаган эш эшләмәгән. Аңа беркайчан да Алладан кичерү сорарга туры килмәгән. ә без, киресенчә, Алладан гөнаһларыбызны яшермәскә тиешбез. Әгар без моны эшләмәсәк, без Алланы да, үзебезне да алдарбыз. Давыт пәйгамбәр Алладан күз яшьләре түгеп кичеру сораган, һәм Алланың дусты Ибраһим да Аннан кичерү сорарга тиеш булган. Ләкин, Тәуратне (Библия) һәм Коръәнне укып чыкканнан соң, син бер генә жирдә дә Гайсәнең кичерү сораганын курмәссең.

Шулай итеп, Гайсәнен бер генә дә кимчелеге булмаган, шуна күрә Ул гөнаһларыннан арынуга мохтаж булмаган. Ул үзенең дошманнарына ачыктан-ачык әйткан: „Сезнең кайсыгыз Мине гөнаһта гаепләр?“ Аларның берсе дә бер генә хатасын да күрсәтә алмаган. Рим прокураторы алдында үзенең соңгы суд эшләрендә судья өч тапкыр рәсми рәвештa белдерә: „Мин бу кешедә бернинди дә гаеп тапмыйм“.

Һәм шуның өстенә, бер юләрләнгән кешенең жанында яшәүче җен, Гайсәнең килүен куреп, болай дигән: «Әй, назаретлы Гайсә, Синең бездә ни эшең бар? Син безне һәлак итәргә килгәнсең! Мин Синең кем икәнеңне беләм. Син – Алланың Изгесе!» Моның

шулай икәнлеге бу дөньяда да, мәңгелектә дә билгеле, Гайсә чиста, камил, изге, Аңа тиңнәр һәм тигезләр юк! Аннан башкалар гына бар да гөнаһлы!

## ГАЙСӘ ӘЙТКӘН СҮЗЛӘРДӘН СИН НӘРСӘЛӘР АҢЛАДЫҢ?

Бөтен пәйгамбәрләр, Гайсә шәкертләре һәм Алланың изге илчеләре Алланың Рухы белан илһамланган, Аның сузен алганнар. Ләкин Гайсә үзе шул Сүз булган. Анда Алланың бөтен илһам көче тупланган. Ул сөйләп кенә калмый, үзе сөйләгәннәрне тормышка да ашыра. Аның тормышында сүз белән гамәл арасында бернинди аерылу да юк. Аның турында без еш кына мондый сүзләрне укыйбыз: «һәм Гайсә бу сүзләрен сөйләп бетергәннән соң, халык Аның өйратуенә хәйран калды, чөнки Ул аларны канунчылар (һәм фарисейлар) кебек түгел, бәлки вәкаләтле зат кебек өйрәтте».

Аның дошманнары үзләренең хезмәтчеләрен Аны эләктереп алырга дип жибәргәндә, хезмәтчеләр кире борылып кайттылар. Алар беркайчан да, беркемнең дә Мондый Кешене күргәннәре булмаганлыклары турында әйттеләр.

Гайсәнен Ул үзе әйткән берничә сүзен тыңла:

– Мин дөньяның яктысы: Минем артымнан барган кеше караңгылыкта йөрмәс, бәлки аның тормышы якты булыр.

– Дошманнарыгызны яратыгыз, сезгә ләгънәт укучыларга фатиха бирегез, сезне нәфрәт итүчеләргә яхшылык итегез, сезне кыерсытучылар һәм эзәрлекләүчеләр өчен дога кылыгыз.

– Хокем итмәгез, үзегезне да хөкем итмәсләр: чөнки нинди хөкем белән хөкем итсәгез, үзегез дә шулай хөкем ителерсез һәм нинди үлчәү белән үлчәп бирсәгез, сезгә дә шундый үлчәү белән үлчәрләр.

Әгәр син бу сүзләрнең мәгънәсе турында тирәнрәк уйлансаң, анларсың, Гайсә чынлап та – дөньяның яктысы. Ул Аның сүзләрен йөрәкләренә якын алган кешеләргә тынычлык һәм чын тормыш бирер.

Калган барлык пәйгамбәрләр Алла нурының кисәкләрен алганнар. Аларны баеп баручы айның йомшак, нурлары белән чагыштырып булыр иде. Гайсә Христос – барлык көченә яктыртучы Кояш. Шуңа күрә Кояш чыкканда кем ярымай артыннан барсын?! Христос – чын нур: Ул дөньяга Алланың чынбарлыгын алып килгән, Аның законының камиллеген алып килгән. Болар бөтенесе дә мәхәббәт дип атала. Ул үзе – гәүдәләнгән мәхәббәт, һәм шуңа күрә Ул әйтә ала: „Күк белән жир бетәчәкләр, әмма Минем сүзләрем бетмәячәк“ һәм „Мин – юл, хакыйкать һәм тормыш“.

# ГАЙСӘНЕҢ КОДРӘТЕ ТУРЫНДА СИН НӘРСӘ УЙЛЫЙСЫҢ?

Гайсәнең эшләре турында белгән кеше, Аның бетмәс-төкәнмәс кодрәте турында уйланмый калмас. Аңа күкнен барлык көчләре һәм хакимияте бирелгән. Ул дөньяга Алла эшләрен алып килгән. Жирдәге бер генә кеше дә Ул эшләгән эшләрне эшли алмый. Ул үзенең сузләре белән авыруларны терелткән. Ул сукырларның кузен ачкан. Сүзе белән Ул давылларны баскан. Ул шайтан-җеннәрне куып жибәргән. Биш ипи һәм ике балык белән Ул 5000 ач кешене тукландырган. Жирдә моңарчы андый кеше яшәмәгән.

Кайбер пәйгамбәрләр Алла хакына дип кайбер чикләнгән могжизалар ясаганнар, Гайсә могжизаларны үзенең куәте белән, үзе хакына ясаган.

Елеон тавында бер авылда Лазарь исемле кеше яшәгән. Ул үлгән һәм аны күмеп куйганнар. Аның туганнары бик нык кайгырганнар һәм елаганнар. Алар Гайсәдән аларның кайгысында Аның ярдәм итуен сораганнар.

Гайсә алар авылына килгән вакытта Лазарь инде дүрт көн кабердә яткан була. Гайсә аның янына килә һәм каты кычкырып: «Лазарь! Чык!» – ди. һәм, чынлап та, үлгән кеше кабердән тере килеш чыга.

Ул вакытта бу кеше белән булган хәл сиңа да кагыла: әгәр син Алланын үлгәннәрне Терелтучесенең тавышын ишетәсең икән, табутыңда торып утыр һәм

узеңнең гөнаһларыңны калдыр, чөнки Гайсә әйтә: «Мин – терелу һәм тормыш; Миңа иман иткән кеше үлсә дә яшәр». Бервакыт шундый көн килер, барлык мәетләр Гайсә тавышын ишетерләр һәм терелерләр:

берәүләр Алла белән мәнгелек тормыш өчен, икенчеләр куркыныч хөкем өчен. Шуңа курә Гайсәгә хәзер йөрәгенне ач, һәм ожмах жимешләре, мәңгелек тормыш синең өчен булыр.

Син үз улемең белән үләсеңме, әллә автомобиль катастрофасына эләгәсеңме? Син ничә яшьтә үләсең? Ничәнче айда һәм кайсы көндә? һәм сине үлгәннән соң нәрсә көтә? Синен туганнарың узләрен ничек тотарлар?

Без узебезнең улемебез турында алдан берни дә белмибез. Пәйгамбәрләр дә узләренең соңгы сәгатьләрен белмәгәннәр. Ләкин Тәңребез Гайсә Христос үзенең Иерусалимда, уз халкының дошманнары тарафыннан үтереләсен алдан ук әйтә. Үзенең теләкләрен искә алып, Ул үзе үләчәк көнне билгели: Пасха бәйрәме вакытында диндар кешеләр үзләренең бәрәннәрен Аллага корбан итеп чалганда. Шулай итеп Христос Алланың бәрәне шикелле итеп улә, үзе белән дөньяның гөнаһларын алып китә, аңа ышанган кешеләрне Алланың ачуыннан саклый. Кем Гайсәгә ышана, шул Аның мәңгелек дөреслегендә гаебен юа, чистара.

Христос үзенен үлеменең сәгатен һәм ничек итеп үләсен генә әйтеп калмый, әмма аның әһәмиятен дә әйтә. Үзенең шәкертләренә Ул үзенең өченче көнендә тереләсен һәм беркем дә Анын терелуенә комачаулык итә алмаслыгы турында да ышандыра. Барысы да Ул дигәнчә була.

Христос әйтә: „Аны (тормыш) Миннән беркем дә алмый, бәлки мин аны үзем бирәм; аны бирерга дә кодрәтем бар, кабат алырга да кодрәтем бар“. Бер генә кеше дә узенең ничек итеп үләсен күз алдына китерә алмый һәм бигрәк тә үзенең үлеме һәм терелүе белән идарә итә алмый. ә Гайсә үз теләге белән үлә, дөньяның гөнаһларын үзе белән алып китүе өчен. Ул безне гөнаһлардан чистарту өчен үлә. Әмма Ул терелтүче дә, яшәеш бирүче дә, Аңа ышанучыларга тормыш бирүче дә. Жирдә бер генә, Гайсә кебек, үлеп терелүче кеше юк! Аның үлеме – Алланың барлык кешелек өчен бөек теләге.

# ГАЙСӘНЕҢ ҮЛЕМ ӨСТЕННӘН ЖИҢҮЕ ТУРЫНДА СИН БЕЛӘСЕҢМЕ?

Гайсә чынлам та үлә һәм кыяга кисеп ясалган каберлеккә күмелә. Аның дошманнары каберлекнең тишеген зур таш белән бастырып куялар һәм керү юлын бу вакытта рим дәүләтендә кулланыла торган иң куәтле печать белән ябып куялар. Алар моны Гайсәнең шәкертләре төнлә килеп үзләренең укытучыларының мәетләрен урламасыннар өчен эшлиләр. Шул сәбәп белән алар керү юлына кораллы сакчылар да куялар.

Әмма өч коннан соң Гайсә терелә һәм узенең каберлеген ташлап китә. Аның шәкертләре аның буш икәнлеген күрәләр. Алар, тере үлеп терелүчене кургәч, тагы да гажәпләнәләр. Алар башта өрәк күрәбез дип, бик куркалар. Ул алар белән әйбәт кенә сойләшә һәм аяк-кулларындагы кадакланган эзләрне күрсәтә. Ул алар каршында ашап күрсәтә, узенә кагылырга рөхсәт итә. Бу моны Аның терелүенә ышансыннар өчен эшли.

Барлык шәкертләр дә һәм пәйгамбәрләр дә үлгәннәр, аларның тәннәре мәеткә әйләнә, сөякләре генә кайбер очракларда сакланып кала, әмма Христос яши, Ул терелә, Ул үлемне жиңә!

Син Христосның үлеп терелүенең бөек әһәмиятен аңладынмы инде? Бу бөек вакыйга белән Алла Тәрегә кадаклангаnны яратуын, Аның корбан үлемен кабул итеп алуын күрсәтә. Шуңа курә Христосның терелүе безгә дә, безнең Алла белән дус икәнлегебезне, дусла-

шуыбызны курсәтә. Шуңа күрә, Гайсә яшәгәнгә курә без кичерелгәннәр!

## ГАЙСӘНЕҢ АЛЛА ЯНЫНА КҮТӘРЕЛҮЕ ТУРЫНДА СИН НӘРСӘ УЙЛЫЙСЫҢ?

Син Христосның күккә ашуы һәм Алланың уң кулына әверелүе турында укыдынмы? Ул – Аллага иң якын. Аңа тиннәр юк! Башта Ул күктән иңә һәм кешегә әверелә, аннан Ул күккә аша һәм шайтанны жиңә.

Христос – кеше белән Алла арасындагы бердәнбер һәм дөрес илче. Барлык Аллага ышанучылар өчен Аның хакына илче. Аның изге илчелегенә ышанучыларның  йөрәкләрендә Изге Җан урнашыр һәм алар үзләренең яңаруларын сизәрләр. Алар бүген үк мәңгелек тормыш алырлар. Әгәр син чынлап та Христосның бүген дә яшәгәненә ышанасың икән, Аның котылуы сиңа да кагылуын телисең икән, үзеңнең йөрәгеңне Изге Рухның көченә ач. Инҗилдән син Гайсәнең кем икәнлеген беләсең, һәм Аның ихтыяр көче белән син томышыңны дәвам итәрсең

Гайсәнең исәнлеген кире каккан кешеләр бер үк вакытта Алланың үзен дә кире кагалар. Ул Гайсәне бөтен кешеләрнең гөнаһлары өчен корбан итеп бирде һәм Аны күктә узенең уң кулы итеп билгеләде. Шуның

белән бергә Алла үзенең алдан күрүчәнлеген исбат итте. Давыт пәйгамбәр күккә ашкан Христос турында әйткәнчә: „Синең дошманнарыңны Синең аягын астына салганга кадәр Минем уң ягымда утыр“. Христосның җиңүле күккә ашуы белән Христосның Аллага булган мәхәббәтенә ышанмаучылар үз-үзләрен гаепкә тартырлар. Бары Гайсәдә генә – Алланың барлык кешеләре өчен изге теләге. Кем дә бу теләкне кире какса, шул Алланың иң ачы каһәренә юлыгыр, чөнки алар Алланың үзе тарафыннан тәкъдим ителгән бердәнбер котылу юлын кире кагалар.

Әмма, минем уйлавымча, син акыллы, һәм Алланың мәхәббәтен кире какмассың, син Христос биргән котылуны кабул итеп алырсың. Аның җиңүле терелүенә кадәр барлык кешеләр өстеннән үлем хакимлек иткән, ә менә хәзер Христос үлемне җиңде һәм доньяга тере булып әйләнеп кайтты. Ул башка беркайчан да үлмәячәк! Кем дә кем Аның белән берләшә, шул аның Алла тормышынын бер өлешен ала, аңа хәтта тәмуг та куркыныч тугел. Сиңа бер сорау бирергә рөхсәт ит: Христосның терелүендә син Алланың мәрхәмәтлелеген күрдеңме һәм син Аны үзеңнең Коткаручың дип кабул иттеңме? Син Аны кабул ит, һәм син мәңге яшәрсең!

# ГАЙСӘНЕҢ ҖИРГӘ ИКЕНЧЕ ТАПКЫР КИЛҮЕ ТУРЫНДА СИН НӘРСӘ БЕЛӘСЕҢ?

Христос – тормышка ашкан мәхәббәт. Ул һәркемне ярата, аеруча Аның ярату Рухы белән килешүчеләрне. Бу кешеләр Аның көче белән үзгәргәннәр. Алар үзләренең дошманнарын кичерәләр, чөнки Алла да Христос хакына кичерде.

Күкта яшәүче Алла безне һәрвакыт үз янында тотарга тели, чөнки Ул безне ярата. Христос узенең үлеме һәм кабат тереүе турында әйткәндә, икенче тапкыр киләчәге турында да әйтә. Акыл ияләре Христос белән очрашуга әзерләнәләр һәм алар Аның бу тормышка яңадан киләчәгенә тулысынча ышаналар. Аның коткаруын кабул итүчеләрне ул үз канаты астына алыр, ә Христосның яхшы теләкләреннән баш чөерүчеләрне аерып куяр.

Кадерле абыйлар һәм апалар! Христос белән очрашуга әзерләнегез! Ул – бердәнбер, синең Коткаручың.

Бөтен дингә ышанучылар да Христосның килүен телилар һәм көтәләр. Яһүдләр дә, мөселманнар да Аның киләсен беләләр. Кайбер кешеләр Христос үзенең икенче килүеннән соң җирдә 40 ел хакимлек итәр, диләр; икенчеләре: юк, Аның хакимлеге 100 ел дәвам итәр, диләр! Тагы да кайберләре ул дөнья белән 1000 ел идарә итәр, диләр. ә Инҗил әйтә: Христос – Патшаларның Патшасы һәм хакимнәрнең Хакиме һәм Аның идарә итүенә чикләр булмаячак, – ди. Ул мәңге дәвам

итәр. Ул үзе дә әйтте: „Мин – Патша. Мин хакыйкать хакында шаһитлык бирү өчен туганмын һәм дөньяга да шуның өчен килдем; Хакыйкатьне яклаучы һәркем Минем тавышымны тыңлый“.

## ХРИСТОСНЫҢ ИСЕМНӘРЕ ТУРЫНДА СИН НӘРСӘ БЕЛӘСЕҢ?

Кайбер пәйгамбәрләрнең үзләренең аерым мактаулы исемнәре бар. Ибраһимны „Алланың дусты“ дип йөртәләр, Мусаны – Алла белән сөйләшүче“, – диләр, Гайсәне – „Алланың тормышка ашкан Сүзе“, – диләр. Инҗилдән без:

„һәм шул күк эченнән: „Бу Минем Сөекле Улым. Мин Аның белән ризамын; Аның сүзен тыңлагыз“, – дигән аваз килде“, – дип укыйбыз.

„Алла Улы“ дигән әйтемне сез ничек аңлыйсыз? Гадәттә малае атасының сурәтен чагылдыра. Шулай ук Гайсәдә дә Алланың барлык теләкләре чагылыш таба. Гайсә үзенең шәкертләренә әйтә: „Мине күргән кеше, әтиемне курер“, – ди. Бәлки, син эчеңнән генә уйлыйсыңдыр: „Ходаем, мине бу уйларымнан арындыр! Мәрьямнең Улы Синең бары пәйгамбәрең генә!“ Алайса синнән сорарга рөхсәт ит: „Ни өчен син Аның артыннан китмисең? Ни өчен син Ул кушкан эшләрне

эшләмисең?“ Әгәр син Аңа узеңнең гөнаһларыңны ярлыкауны сорап мөрәҗәгать итмәсәң, Аңа сине, синең уйларыңны, сүзләреңне, эшләреңне узгәртергә ирек бирмәсәң, син хөкем ителерсең.

Христосның бу дөньяга кол рәвешендә килүе, безне, гөнаһ колларын коткарырга килүе бөек сер. Ул бу дөньяга иң басынкы кеше рәвешендә килә, безгә миһербанлылык һәм шәфкатьлелекнең әһәмиятен аңлата. Горурлык та, хакимият тә, байлык та безне коткара алмый, бары тик Алланың мәхәббәте генә коткара. Кулыңда кылыч һәм автомат тоткан кеше көчле булып күренергә мөмкин, ләкин кем үз-үзен жиңә, шул гына көчле. Ләкин иң бөек кеше Шул, Кем үзен үзе бүтәннәрне коткару өчен корбан итә.

Яхъяның сүзләрендә нәкъ менә шул мәгънә ята: „һәм Сүз тән булды. һәм мәрхәмәт, һәм хакыйкать белән тулы булып, безнең арабызда яшәде һәм без Аның данын, Атаның бердәнбер Улының данын күрдек... һәм Аның тулылыгыннан без һәммәбез мәрхәмәт өстенә мәрхәмәт алдык“.

Христос кеше кыяфәтендәге тән булды, шуңа күрә без әйтә алабыз, Алла – бизнең Атабыз, мәрхәмәтле, мәхәббәтле һәм кичерә алучы. Алла – жимерүче һәм харап итүче түгел, узенең иҗат җимешен язмыш кочагына ташлап калдыручы һәм аның турында башка кайгыртмаучы да түгел. Христос безгә аңлаешлы итеп Алланың билгеләмәсен ачты. Ул безгә „әти“ сузен генә ачып калмады, ә бәлки үз үзе белән Аның гажәеп

характерлы якларын, Аның мәхәббәтен алып килде. Ул моны без мәңгелек тормышның төбен, мәгънәсен аңласын өчен күрсәтте, тормышның мәгънәсе – мәхәббәт, бары тик Алланың изге яратуы гына!

## ХРИСТОС ТӘКЪДИМ ИТКӘН БАРЛЫК НӘРСӘЛӘРГӘ СИН НИЧЕК КАРЫЙСЫҢ?

Алла Улы сиңа һәм барлык кешеләргә дә әйтә: „Барлык тырышып эшләүчеләр һәм йөкләре авыр булганнар, Миңа килегез һәм Мин сезне тынычландырырмын; Минем камытны үзегезгә алыгыз һәм Миннән өйрәнегез, чөнки Мин юаш һәм басынкы күнелле, һәм үзегезнең җаныгызда тынычлык табарсыз; чөнки Минем камытым кулай, һәм Минем йөгем җиңел“.

Гайсә узенең укучыларына шушындый сүзләр белән мөрәҗәгать иткәч, алар торып бастылар, үзләренең өйләрен, ата-аналарын, эшләрен калдырдылар һәм Аның артыннан киттеләр. Алар Анда Алла көче барлыгын үзләрендә тоеп белделәр. Алар Аның артыннан никадәр озаграк барсалар, Аны шуның кадәр яхшырак белделәр. Алар Аңа шулай итеп ышандылар һәм Аңа узләренең бөтен тормышларын багышладылар. Ул аларга үзенең Изге Рухын бирде. Бу Рухның Көче белән алар яшәделәр һәм үзләренең сөекле Тәңреләрен

көттеләр. Христос синнән дә шушындый ук эшләр көтә. Ул сине чакыра. узеңнең барлык нәрсәңне калдыр да, Аның артыннан бар! Син Аны тагы да яхшырак белә башларсың һәм узеңнең тормышыңны Аның ышанычлы кулларына тапшырырсың. Ул сиңа узенең Изге Рухын бирер, һәм син узеңнең эшләреңне Аның мәхәббәтенә карап үзгәртерсең. һәм син дөреслек сөюче, буйсынучы булырсың, һәм бөтен акыллардан да өстенрәк булган Алла дөньясы синең йөрәгеңне һәм уйларыңны чиста, изге итеп, Тәңребез Гайсә Христос килгәнче саклар.

Кадерле укучы! Син Гайсә турындагы бу китапчыкны бик игътибар белән укып чыктың, шуңа күрә сиңа түбәндәге сорауларга җавап бирүе авыр булмас. Әгәр де син бу сорауларның күбесенә дөрес җавап бирә алсаң һәм үзеңнең җавапларыңны безгә җибәрсәң, без сиңа икенче кызыклы „Христосның шәхесе Инҗилдә һәм Коръәндә“ дигән китап җибәрербез яисә башка берәр яхшы китап җибәрербез.

**Сораулар:**

1. Христосның тууында нәрсә гаҗәеп була?
2. Ни өчен Христос беркайчан да гөнаһ кылмый, дөрес һәм изге булып кала?
3. Гайсә кылган кайсы гаҗәеп хәл сиңа күбрәк тәэсир ясады?
4. Христосның сүзләре сиңа нинди серне чиште?
5. Христосның үлемендә үзенчәлекле нәрсә бар?
6. Христосның үлеп терелүе нәрсәне аңлата?
7. Христос хәзер кайда яши һәм нәрсә белән шөгыльләнә?
8. Христосның килүе нәрсәне аңлата?
9. Син үзең Христос турында нәрсә уйлыйсың?

---

Үзеңнең җавапларыңны түбәндәге адрес белән җибәрә аласың:
420132, Казань, ул. Адоратского 37–97

# ХРИСТОС ТУРЫНДА СИН НӘРСӘ УЙЛЫЙСЫҢ?

АБД-ЭЛЬ-МАШИ